**Республика Татарстан**
**Старо-Имянское сельское**
**поселение Сармановского**
**муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль**
**районының Иске Имән**
**авыл җирлеге**

---

**КАРАР**
**07.02.2025 ел**

**КАРАР**
**№125**

«Җир салымы турында» 2020 елның 27 февралендәге 145 номерлы карарга үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Иске Имән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Иске Имән авыл җирлеге Советы карар итте:

1.Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 27 февралендәге 145 номерлы карарына (Советның 2020 елның 12 ноябрендәге 11 номерлы , 2023 елның 22 февралендәге 73 номерлы, 2023 елның 02 ноябрендәге 84 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1) 2 пунктта «кадастр бәясеннән» сүзләрен төшереп калдырырга;
2) 1.2.1 Пункт. түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән (торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлегенең өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән), әлеге абзацта күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән тыш, эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләрен һәм аларның һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган җир кишәрлекләрен;»
3) 1.2.2 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:
«4) Шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата 0,15%

"Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында», әлеге абзацта күрсәтелгән һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артык җир кишәрлекләреннән тыш;"

4) Пункт 2 «Рөхсәт ителгән файдалануның бер төреннән артыграк булган җир кишәрлегенә карата җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалануның шушы җир кишәрлеге өчен билгеләнгән кадастр бәясе (салым базасы) туры килә торган төренә карата билгеләнгән салым ставкасын кулланырга кирәклеген билгеләргә";

5) 4 пунктны «Салым салудан азат итәргә:" дип бәян итәргә

6) 4.1. пунктын төшереп калдырырга

7) 5 пунктта «,өлеш»сүзен төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге Советының 2025 елның 15 январендәге «Сарман районы Иске Имән авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 27 февралендәге 145 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 124 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» халыкка җиткерергә (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2025 елның 01 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге
Советы рәисе Р.Ә.Исламова